**Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт урынында үз-үзләрен тотышы буенча**

# РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР

## Хезмәткәрләрнең тышкы кыяфәте

Өс киеме чиста һәм пөхтә, эш стиле сакланган булырга тиеш.

Спорт өс киеме, аяк киеме рөхсәт ителми. Аяк киеме чиста һәм пөхтә булырга тиеш.

Бөтен эш көне дәвамында хезмәткәр оешма исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм белгечнең вазыйфасы язылган бейдж йөртергә тиеш.

Костюмга төрле аксессуарлар һәм күп санлы булмаган, күзгә ташланып тормаган бизәнү әйберләре өстәү рөхсәт ителә.

Чәчләр чиста һәм пөхтә итеп җыеп куелган булырга тиеш, экстравагант прическалар йөртү киңәш ителми. Урта звено хатын-кызлары өчен таратылган, әмма пөхтә итеп таралган чәчләр белән йөрү рөхсәт ителә.

Макияж тыйнак булырга тиеш. База тоны – ачык яки аксыл көрән төсләр. Ачык төсләр һәм ялтыравыклар куллану киңәш ителми.

Куллар яхшылап каралган, тырнаклар озын түгел, ачык төскә буялмаган.

Хушбуй исе (ислемай, дезодорант) артык көчле булмаска тиеш.

Аксессуарлар һәм бизәнү әйберләре күп санлы, күзгә ташлана торган һәм күләмле булмаска тиеш.